**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР

2021 нче елның «10» февраленнән № 63

## Авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче аерым гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында» 2005 елның 20 апрелендәге 192 номерлы карары (2019 ел, 16 июльдә кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү чыгымнарының Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән социаль норма чикләрендә 100% күләмендә социаль ярдәм чараларын һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләрдән файдалану нормативларын түбәндәге категория гражданнарга билгеләргә:

мәдәният өлкәсе хезмәткәрләренә - торак, җылылык, ут өчен түләү. Социаль ярдәмнең күрсәтелгән чарасы авыл җирендә урнашкан мәдәният һәм социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә 10 елдан да аз эшләмәгән һәм анда яшәүче, пенсиягә чыккан хезмәткәрләр өчен дә сакланып кала.

Социаль ярдәм чаралары алучы гражданнарның салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча Россия Федерациясе салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле процентлар, шулай ук Россия Федерациясе бюджет системасы

бюджетына кире кайтару буенча кичектерелгән бүтән бурычлары булмаска тиеш.

2. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына социаль ярдәм чараларын адреслылык принцибын үтәү һәм мохтаҗлык критерийларын куллану бурычларыннан чыгып бирү һәм камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында" 29.12.2015 ел, № 388-ФЗ Федераль закон нигезендә социаль ярдәм чараларын бирүче оешмаларга социаль ярдәм чараларын бирү турында мәгълүмат тапшыруны социаль тәэминатның Бердәм дәүләт мәгълүмат системасыннан файдалану юлы белән (алга таба- ЕГИСО) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә һәм ЕГИСО операторы билгеләгән форматларга туры китереп тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәгеге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http:/pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының “Авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче аерым гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында "2020 ел, 23 декабрь, 348 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль эшләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фәсахов